**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ДӘВЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 ел,20 гыйнвар №178

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлегенең Совет депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6нчы октябрендәге № 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы" федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советы карар итте :

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 августындагы "Совет депутаты статусы нигезләмәсе хакындагы" 64 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) Шәхси яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә,түбәндәге очраклардан тыш, катнашырга:

сәяси партия белән, профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында,муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасын сайлап алучы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга,съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу;

- коммерцияле булмаган оешма белән (сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек хуҗалары ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы югары вазыйфаи затына (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп түләүсез рәвештә катнашу;

- Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советында, Муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

- муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган, муниципаль берәмлек исеменнән оешма вәкаләтләрен гамәлгә кую тәртибен йә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр белән) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә яклау;

- федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш бүтән түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында Дәвеш авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Дәвеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Дәвеш авыл җирлеге Башлыгы** **Т.Т.Хөсәенов**